Балалар бакчасы – балачакның гомер буена истә калырлык бәхетле бер мизгеле. Безнең балалар бакчасының утыз еллык тарихы бар. 1982 елның 12 нче июлендә нәни дуслар беренче тапкыр бакча бусагасын атлап керәләр.

Ул вакытта бакча ПМК – 90 оешмасына караган һәм “Теремкәй” исемен йөрткән. Бу вакыт эчендә күп әйбер үзгәргән: бакчаның исеме алышынган, хезмәткәрләр, мөдирләр үзгәреп торган, әмма балаларга карата мәхәббәт үзгәрешсез калган.



***«Теремкәй» - балалар бакчасының беренче исеме***



***8нче номерлы “Гөрләвек” балалар бакчасы безнең көннәрдә***

Безнең балалар бакчасы Ворошилов урамының 19 нчы йортында тимер юл тирәсендә урнашкан.

Балалар бакчасын беренче мөдир – Баһаутдинова Гүзәл Гобай кызы ачкан. Ул мөлаем кеше, педагоглар, ата-аналар, балалар белән уртак тел таба белүче яхшы җитәкче.



***Балалар бакчасын ачу, 1982нче елның июль ае***

Эшләү дәверендә ул территория үстерүгә күп игътибар биргән, күп көчен дус коллектив оештыруга багышлаган. Белем дәрәҗәләре туры килмәсә дә, коллетивта балаларны яратучы, ягымлы, яхшы күңелле кешеләр эшләгән. Беренче көннән үк Гүзәл Гобай кызы җитәкчелегендә методист Султанова С.П., Сайфутдинова Н.Г., Галеева М.М., Васильева Г.К., музыка җитәкчесе Аюпова А.А., логопед Нигъматҗанова Р.Г., тәрбиячеләр Насыбуллина З.С., Низамиева М.А., шәфкать туташы Марзия Низам кызы, ярдәмчеләр Наилә, Валя, пешекчеләр Гөлсинур, Мәргүбә, Наилә, Җәвәһирә, кер юучылар Нурия, Вәсилә эшләгән. Шушы коллектив беренче чыгарылыш балаларын мәктәпкә озаткан.

1985 елда бакча тормышында яңа этап башлана. Еллар дәверендә коллектив ныгый, эш тәҗрибәсе арта. Җитәкчелек эшен Грачева Газима Борис кызы дәвам итә.

90 нчы елларда балалар бакчасының исемен “Гөрләвек” дип алыштыруга карамастан, халык телендә “Теремкәй” дип йөртелә.



***Беренче тәрбиячеләр һәм беренче чыгарылыш, 1983 ел***

Грачева Газима Борис кызы – “Халык мәгарифе отличнигы”, дүрт бала анасы, дәү әни, егерме ел буе балалар бакчасы белән җитәкчелек иткән. Белеме буенча биолог буларак ул бакча территориясен ямьләндерүгә күп көч куйган. Коллектив белән берлектә унбиш төрдән артык агачлар һәм куаклар утыртылган.



***Грачева Гәзимә Борис кызы, 1985-2005 елларда мөдир, “Халык мәгарифе отличнигы”***

Ул җитәкче булган чорда балалар бакчасы коллективы һәм тәрбияләнүчеләре төрле иҗади конкурсларда актив катнашалар.

Валеева Р.М., Самигуллина М.Р., Бадрутдинова А.А., Хафизова О.М., Гаязова Г.Ш., Абдуллина Р,А. кебек тәҗрибәле белгечләр белән беррәттән, яшь педагоглар: Канышева С.М., Родыгина Р.Г., Сайфуллина Д.Г., Сахабутдинова Г.Г.лар үз эшләрен башлап җибәрәләр.



***Чыгарылыш, 1995 ел***


Алар үзләренең тәрбияләнүчеләренә йөрәк җылысын, назын, мәхәббәтен бирәләр. Педагоглар балаларның белем дәрәҗәләрен арттыралар, игътибар һәм наз бүләк итәләр.

Валеева Р.М. берничә буын балаларын тәрбияли. Ризидә Мәхмүт кызы – яхшы күңелле, иҗади кеше. Ул балаларга тәрбияче генә булып калмый, әни,



***Тәрбияче Валеева Ризида Мәхмүт кызы, 1982-2016 еллар***

дәү әни дә була.Төркемдә аның белән балаларның вакытлары кызыклы, күңелле үтә. Балалар өй атмосферасында тәрбияләнәләр.



*Пешекче Гульсинур апа – үз эшенең остасы*

Ризидә Мәхмүт кызы болай дип искә ала: “Минем гомерем шушы балалар бакчасында үтте. Безнең коллектив бердәм, дус булды. Балаларны да карый идек, өйдәге эшкә дә җитешә идек. Эш хакы кечкенә булуга карамастан, ике бала үстердем. Һәр тәрбияләнүче миңа үз баламдай якын булды. Бу елларда пешекче булып Гульсинур апа эшли иде. Ул үз эшенең остасы. Аның кулы белән әзерләнгән ризыклар тел йотарлык, чөнки ул бар күңелен биреп эшләде.”



***Өлкән тәрбияче,***
***Якупова Лилия Маннемулла кызы,***
***1990-2011 еллар***

Якупова Лилия Маннемул кызы – ясле бакчасының методисты, ул коллективта зур хөрмәткә ия кеше. Эшенә иҗади якын килеп эшләүче, педагоглар өчен үрнәк була. Аның җитәкчелегендә балалар бакчасында методик эш тагын да камилләштерелә, район семинарлары үткәрелә, педагогик коллектив республика һәм район конкурсларында җиңү яулый.

Лилия Маннемул кызы ярдәмендә методик кабинет җиһазландырыла, күрсәтмә һәм таратма материаллар тулылана. Ул бик күп яшь белгечләргә, мәктәпкәчә тәрбия бирү методикасын югары дәрәҗәгә күтәрергә булыша. Тәрбиячеләр белән беррәттән үткәрелгән бәйрәмнәрдә актив катнаша.



***Хуҗалык мөдире, Каюмова Сәймә Сөләйман кызы,***

***1995-2011 еллар***

Үзенең 12 ел эш дәверендә, хуҗалык мөдире Доронина Нургаян Магьсум кызы, бакчабызны җиһазлар белән тәэмин итүдә зур өлеш кертә. Аның эшен Каюмова Саймә Сөлейман кызы дәвам итә, 18 ел гомерен бакчага багышлый.

Балаларны медицина хезмәте күрсәтү белән дә тәэмин итү кирәк була. Бу эшне шәфкать туташы – Насыбуллина Зоя Семен кызы башкара.Ул бакчада 31 ел буе эшли.



*Шәфкать туташы Насыбуллина Зоя Семен кызы, 1982-2016 еллар*

Яруллина А.Ф., Сайфуллина А.Н., Сапаркина А.Н., Васильева Л.А., Захарова Р.К., Аксанова В.С., Шакирова Г.П., Гильмутдинова Д.М., Галимзянова С.Х., Хамиева Х.Ш., Шарипова М.М., Сәляхова М., балалар бакчасында озак еллар буе эшләп лаклы ялга чыгалар.

Билгеле бер чорда Ишимова О.Н., Сафина Т.Р., Галеев К.С., Идиятуллина Л.Х., Ахметгалиева Ф.В., Камалова С.Р., Хусаинова Л.Р., Леонтьева Г.Р., Мухлисова Н. бакча тормышында актив катнашып, үз эшләрен намуслы башкаралар.



*Музыка җитәкчесе Рахматуллина Наталия Узбәк кызы, 1990-2006 еллар*

Еллар уза. Коллектив тәҗрибә туплый, осталыгын үстерә.

Музыка җитәкчесе Рахматуллина Наталья Үзбәк кызы бик күңелле һәм кызыклы бәйрәмнәр үткәрә. Көннәр буена залда музыка, җыр яңгырый. Монда балалар әкият һәм бәйрәм атмосферасына чума.

Уен участоклары елдан-ел җиһазлар белән тулыландырыла, яшелләндерелә һәм ямьләнә. Ата-аналар зур ярдәм күрсәтәләр, субботникларга җыелып эшлиләр.



***Мөдир***

***Гайнетдинова Зөлфия Зөфәр кызы***

Югары профессионал сыйфатлы педагогларның даими составы мәктәпкәчә яшьтәге баларга белем бирүдә югары уңышларга ирешүне тәэмин итә. Балалар бакчасында күрсәтелгән хезмәтләр саны арта һәм балаларны мәктәпкә әзерләү сыйфаты үсә. Бакчада логопед пункты эшли, балаларның сәламәтлегенә һәм

физик үсешенә зур игътибар бирелә.

2005 елның 1нче сентябрендә коллектив белән Гайнетдинова Зөлфия Зөфәр кызы җитәкчелек итә башлый. Яшь, энергияле, үз эшенә гашыйк педагог. Балалар бакчасы икенче сулыш ала.

Шулай итеп бакчада яңа тормыш башлана.

Хәзерге вакытта коллектив тулы составта бердәм максатлар һәм бурычлар өстендә эшли, коллективта бердәм рух хөкем сөрә.

Балаларның үсеш һәм тәрбия процессын тәэмин итүче педагоглар коллективы унбиш кешедән тора. Педагогларның күбесе унбиш елдан артык эшләүче зур тәҗрибәле тәрбиячеләр, даими рәвештә профессионал дәрәҗәләрен үстерәләр, яшь педагогларга эш серләрен өйрәтәләр. Педагогларның эшләренә югары бәя бирелә, күпсанлы грамоталар шуны дәлилли. Ун педагог беренче һәм югары квалификациягә ия.

Балаларга әхлакый тәрбия бирү милли региональ компонентка нигезләнеп эшләнгән укыту-методик комплект ярдәмендә, көн дәвамында, балалар һәм ата-аналар белән эш аркылы алып барыла. Татар телен өйрәтү өчен мультимедиа җиһазлар, ноутбуклар һәм планшет белән тәэмин ителгән. Бакчада күп санда методик әдәбият, таратма, күрсәтмә материаллар, музыка һәм татарча мульфильмнар яздырылган дисклар җыелмасы тупланган.

Группаларда милли үзәкләрне төрләндерү һәм тулыландыру өстендә зур эш алып барыла. Бу үзәкләрдә төрле халык киемнәрендәге курчаклар, Татарстан һәм Россиянең милли символикасы, балаларның яшенә туры килә торган әдәбият, педагоглар тарафыннан эшләнгән методик кулланмалар һәм уеннар тупланган. Һәр төркемдә “Кукмара-горурлыгым минем” дигән үзәкләр булдырылган.



***Төркем бүлмәсе ремонттан соң, 2018 ел***

Балалар бакчасын матди-техник яктан җиһазлау дәвам итә: уен мәйданчыклары яңартылган, бакча территориясен әйләндереп алынган койма буялган, бина һәм төркем бүлмәләренә косметик ремонт ясалган.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен мәгълүмати-коммуникацион һәм визуаль чаралар белән баету өстендә эш алып барыла: график планшет,методик әдәбият, CD дисклар кайтартылган.

Быелгы ел безнен өчен сөенечле: балалар бакчасында капиталь ремонт башланды. Моңа эшчеләр, тәрбияләнүчеләр, әти-әниләр бик шат, чөнки төркем бүлмәләре, кабинетлар яңартыла һәм җылытыла.

Бакчабызда традицион бәйрәмнәр белән беррәттән “Сабантуй”, “Әти-әни һәм мин”, “Тукай бәйрәме”,  “Ачык ишекләр көне”, театраль тамашалар бик күңелле үтә.



***Ачык ишекләр көне, 2017 ел***



***Сабантуй, 2017 ел***

Хәзерге вакытта  безнең балалар бакчасына йөрүче Кукмараның кечкенә гражданнарына үзләренең кайгырту һәм мәхәббәтләрен Гайнетдинова З.З җитәкчелегендәге бердәм коллектив бүләк итә. Укыту-тәрбия эше белән өлкән методист Канышева С.М. җитәкчелек итә. Тәрбиячеләр Сәмигуллина М.Р., Бәдретдинова Ә.А., Гаязова Г.Ш.,Родыгина Р.Г., Хафизова Л.А., Шакирова Д.Р., Галәветдинова Э.Г., Хуҗина Р.Р., Степанова Е.Н үсеп килүче буынны тәрбияләүдә мөһим роль уйныйлар. Татар телен өйрәтү буенча тәрбияче Габдрахманова Э.Н., инглиз теле укытучысы Гайнетдинова Э.Р. балаларга тел өйрәнергә булышалар. Физинструктор Яковлева Н.В. ярдәмендә балалар спорт белән шөгыльләнәләр. Тәҗрибәле укытучы-логопед Закирова Р.Ш нәни дусларына сөйләм деффектларын бетерергә ярдәм итә. Музыка җикәкчеләре Караева Г.Р. һәм Фатхуллина  А.Р  балаларны музыка нечкәлекләренә  өйрәтәләр.

Тәрбиячеләрнең төп ярдәмчеләре булып кече тәрбиячеләр Павлова Г.В., Байметова М.З., Якупова Г.Р., Саляхова Ч.Р., Яруллина Г.Р., Гыйззатова А.М. тора.



***Безнең коллектив, 2018 ел***

Балаларның сәламәтлеген табиб-педиатр Багабиева Л.Х. һәм медсестралар Васильева А.М., Исрафилова Л.Р. кайгырта.

Балалалар бакчасының хуҗалык өлеше белән хуҗалык мөдире Галиуллина Д.Р. идарә итә. Пешекчеләр Юнысова Р.В., Самигуллина Э.Н., хезмәткәр ярдәмчесе Ганеева О.А., кер юучы Бикбаева Г.П., җыештыручы Фадеева М.И., эшче Габбасов И.В. балалар өчен уңайлы шартлар булдыру өчен тырышалар.

Коллективның системалы бердәм эшчәнлеге нәтиҗәсендә безнең балалар "Булачак укучылар", "Йолдызчыклар", "Тылсымчы кыш", "Төсле тамчылар" кебек Бөтенроссия конкурс һәм олимпиадаларында призлы урыннар алалар.

Бөтендөнья күләм бәйгеләрендә, мәсәлән "Look and learn" интернет порталында рәсем конкурсында катнашалар. Шулай ук бездә тәрбияләнүчеләр республика дәрәҗәсендәге узган конкурсларда: "Сомик" интеллектуаль олимпиадасында һәм "Гырон быдтон" удмурт культурасы чагылдырылган республика бәйрәме дәрәҗәсендә үткәрелгән "Без бергә" балалар иҗаты күрсәтмә - конкурсында төрле призлы урыннар алалар. Ел саен районда үткәрелә торган конкурсларда: әниләргә карата җырлар һәм шигырьләр, Ватанны саклаучылар көненә багышланган иҗади сүз һәм сугыш – патриотик җырлар, "Шома бас" бию һәм аерым катнашучылар конкурсларында катнашып төрле призлы урыннар яулыйлар.

Аннан тыш бакча коллективы яңа уку елына әзерлек буенча, "Юннат", "Начар гадәтләргә - спорт альтернатива", "Кардан әкияти шәһәрчек һәм сыннар" район конкурсларында актив катнаша һәм призлы урыннар ала.

Республика күләм конкурсларында сөенерлек нәтиҗәләр бар:

- "Бакчада иң яхшы физик – сәламәтләдерү эшчәнлеге" смотр – конкурсы, 2009 ел, 2 нче урын;
- хезмәтне саклау буенча 5 нче республика күләм смотр – конкурсы, 2010 елда, 2 нче урын;
- балалар юл – транспорт травматизмы профилактикасы буенча республика күләм смотр – конкурсы, 2012 ел, лауреат.

Әмма иң төп горурлыгыбыз - кайчандыр бездә тәрбияләнгән, хәзерге көндә югары дәрәҗәгә ирешкән кешеләр. Алар безнең бакчада алган белем һәм күнекмәләрне файдаланып район һәм республика күләм дәрәҗәсендә күренекле кешеләр булып саналалар.

Мәсәлән:

- Глухова Лариса Юрий кызы – 2013 - 2017 нче елларда Татарстан Республикасы юстиция министры, бүгенге көндә Татарстан Республикасы



***Глухова Лариса Юрий кызы, Татарстан Республикасы Президенты-ның ил – хокук идарәсе җитәкчесе РТ***

Президенты-ның ил – хокук идарәсе житәкчесе;
- Зиятдинова Гөлназ Ринат кызы – 10 нчы номерлы “Ромашка” балалар бакчасы мөдире;
- Валеев Ильнар Илдус малае, Муртазин Илназ Раиф малае, Габидуллин Ильмир Илдус малае, Корбанов Ильяс Илһам малае, Нәҗипова Зөлфирә Марат кызы, Зарипов Марат Азат улы үзләрен табиб һөнәренә багышлаганнар;
- Курбатова Анастасия Валерий кызы – башлангыч сыйныф укытучысы һ. б.

Без аларның карьераларын күзәтәбез һәм алар өчен сөенәбез.

Безнең “Гөрләвек” балалар бакчасы үзенең сөенечләре, көндәлек кайгыртучанлыгы, ачышлары, бәйрәмнәре белән бер зур гаилә шикелле. Анда нәниләргә үзләренең күнел җылысын, дөньяның шатлыклы ачышларын бирүче кешеләр эшлиләр.



***Тарих дәвам итә…***

Без үзебезнең тәрбияләнүчеләребезне хәтерлибез, аларнын казанышлары белән горурланабыз, очрашуларга сөенәбез.

Ә безнең бакчабызның тарихы болай гына тәмамланмый, ул яңа үсеш ала....